**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 6 апрель № 220

г. Казань

Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру кысаларында оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләрен һәм эш эзләүче гражданнарны алдан һөнәргә өйрәтүне һәм аларның стажировкасын оештыруга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 елга Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2015 ел, 18 март, 162 нче карарын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру кысаларында оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләрен һәм эш эзләүче гражданнарны алдан һөнәргә өйрәтүне һәм аларның стажировкасын оештыруга субсидияләр бирү тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Тәртипне куллану буенча аңлатмалар бирү Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\220.doc

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2015 ел, 6 апрель, 220 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру кысаларында оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләрен һәм эш эзләүче гражданнарны алдан һөнәргә өйрәтүне һәм аларның стажировкасын оештыруга субсидияләр бирү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Бу Тәртип оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәктәрләрен һәм эш эзләүче гражданнарны алдан һөнәргә өйрәтүне (алга таба – һөнәргә өйрәтү) һәм аларның стажировкасын оештыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 18 март, 162 нче карары белән расланган «2015 елга Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру» дәүләт программасын (алга таба – Дәүләт программасы) тормышка ашыру кысаларында оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләрен һәм эш эзләүче гражданнарны һөнәргә өйрәтүне һәм аларның стажировкасын оештырганда һәм гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба – Министрлык) һәм Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләре (алга таба – эш белән тәэмин итү үзәкләре) арасында үзара хезмәттәшлек итү тәртибен билгели.

2. Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2015 елда Россия Федерациясе субъектлары хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү һәм бүлү турында» 2015 ел, 22 гыйнвар, 35 нче карары нигезендә эшләнде.

3. Субсидияләр хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыру турында Россия Федерациясе Хөкүмәте белән шартнамә төзегән Дәүләт программасында катнашучылар булган эш бирүчеләргә (алга таба – оешмалар) бирелә.

Оешмаларның исемнәре һәм оешма тарафыннан һөнәргә өйрәнүгә һәм стажировкага җибәрелә торган хезмәткәрләрнең һәм эш эзләүче гражданнарның иң чик саны Дәүләт программасына теркәлгән 4 нче кушымтада күрсәтелә.

4. Һөнәргә өйрәтүдә һәм (яки) стажировкада катнашуга оешмаларның эштән азат итү куркынычы янаган (тулы булмаган эш вакыты билгеләнгән, эшләре вакытлыча туктатып торылган, эш хакы сакланмый торган яллар бирелгән, хезмәткәрләрне эштән азат итү чаралары үткәрелгән) хезмәткәрләре (алга таба – хезмәткәрләр) һәм эш эзләүче гражданнар хокуклы.

Балигъ булмаган балалары булган хезмәткәрләр һәм эш эзләүче гражданнар һөнәргә өйрәтүдә һәм (яки) стажировкада катнашуга өстенлекле хокукка ия.

5. Һөнәргә өйрәтүне оештыру һәм гамәлгә ашыру мәгариф өлкәсендәге гамәлдәге законнар, шул исәптән «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 ел, 29 декабрь, ФЗ-273 нче Федераль закон, Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының «Һөнәргә өйрәтүнең төп программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2013 ел, 18 апрель 292 нче, «Һөнәргә өйрәтү гамәлгә ашырыла торган эшчеләр һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2013 ел, 2 июль, 513 нче, «Өстәмә һөнәр белеме бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013 ел, 1 июль, 499 нчы боерыклары белән регламентлана.

Һөнәргә өйрәтү һөнәргә өйрәтү буенча төп программалар һәм өстәмә һөнәри программалар (алга таба – белем бирү программалары) буенча белем бирү оешмаларында һәм бу программалар буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган һөнәргә өйрәтүне гамәлгә ашыручы оешмаларда (алга таба - белем бирү оешмалары) башкарыла.

Стажировка төшенчәсен һөнәргә өйрәнгәндә алган эш башкару күнекмәләрен турыдан-туры эш урынында гамәли үзләштерү дип аңларга кирәк. Бу вакытта стажировка хезмәткәрне һөнәргә өйрәтү өчен җибәргән оешмадагы эш урынында да, теге яки бу предприятиедәге эш урынында да, оешмада да (шул исәптән хезмәткәрне һөнәргә өйрәтүгә җибәргән оешмага җиһазлар, технологияләр кайтартучы һәм аңа хезмәтләр күрсәтүче оешмада да) гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Өстәмә һөнәр белеме бирү программасы тулысынча яки өлешчә алдынгы тәҗрибәне өйрәнү, яңадан һөнәргә өйрәнү яки квалификация күтәрү программаларын үзләштергәндә алынган теоретик белемнәрне беркетү һәм вазыйфаи бурычларны үтәгәндә алардан нәтиҗәле файдалану өчен гамәли күнекмәләр һәм белемнәр алу максатларында стажировка рәвешендә үткәрелергә мөмкин.

Өстәмә һөнәр белеме бирү программаларын үзләштерүгә хезмәткәрләр һәм урта һөнәр белеме һәм (яки) югары белеме булган яки бу белемне алучы эш эзли торган гражданнар кертелә.

6. Оешмаларга субсидияләрнең гомуми күләме Дәүләт программасының 1 нче кушымтасында «Эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләрнең хезмәт базарындагы конкурентлылык сәләтен арттыру» дигән 2 нче бурычны үтәүгә күздә тотылган акчаның гомуми күләменнән артык булмаска тиеш.

## II. Субсидия бирү тәртибе һәм шартлары

7. Оешмага субсидия бирү Министрлык раслаган форма буенча эш белән тәэмин итү үзәге һәм оешма арасында төзелә торган шартнамә (алга таба – субсидия бирү турында шартнамә) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Субсидия бирү турындагы шартнамәдә субсидиянең максатчан билгеләнеше һәм күләме, субсидияне бирү һәм күчерү тәртибе, вакытлары, субсидиядән файдалану турында хисап кертү тәртибе һәм формасы, аны биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта субсидияне кире кайтару тәртибе, хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияне оешма тарафыннан кире кайтару очраклары, эш белән тәэмин итү үзәге, Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан оешманың субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен, бу Тәртип һәм төзелә торган шартнамә шартларын үтәвенә тикшерүләр үткәрүгә оешманың ризалыгы күздә тотыла.

Субсидия бирү турындагы шартнамәдә шулай ук Дәүләт программасы паспортында күздә тотылган һөнәргә өйрәтүне һәм стажировканы тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү индикаторларының түбәндәге мәгънәләре күрсәтелә:

һөнәргә өйрәнгәннән һәм стажировкаларын тәмамлаганнан соң яңа эш урыннарына урнаштырылган яки эшләре саклап калынган эштән азат итү куркынычы янаган хезмәткәрләр өлеше;

оешмада эшли торган, балигъ булмаган балалар тәрбияләүче ата-аналарның гомуми санында һөнәргә өйрәнүдә һәм стажировкада катнаша торган балигъ булмаган балалар тәрбияләүче ата-аналар өлеше.

Субсидия бирү турында шартнамә өч нөсхәдә – оешма, эш белән тәэмин итү үзәге һәм Министрлык өчен берәр итеп төзелә.

8. Субсидия алу өчен оешма агымдагы елның 1 сентябреннән дә соңга калмыйча үзенең төп эшчәнлеген гамәлгә ашыру урыны буенча эш белән тәэмин итү үзәгенә Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча хезмәткәрләрне һәм эш эзләүче гражданнарны һөнәргә өйрәтү һәм (яки) аларның стажировкасы өчен кирәк булган, бу Тәртипнең 12 нче пункты нигезендә хисаплап чыгарылган субсидия күләме исәп-хисабын үз эченә алган субсидия бирү турында гариза (алга таба – гариза) кертә.

Гаризага түбәндәгеләр теркәлә:

түбәндәгеләрне күрсәтеп, һөнәргә өйрәтүгә һәм (яки) стажировкага җибәрелә торган хезмәткәрләр исемлекләре:

фамилияләрен, исемнәрен, аталарының исемнәрен;

эшчеләрнең һөнәрен, хезмәткәрләрнең соңгы эш урыны буенча били торган вазыйфалары исемнәрен;

һөнәр белемен;

һөнәргә өйрәтү һәм (яки) стажировка оештырылачак белем бирү программасын (әгәр стажировка өстәмә һөнәри программа формасы булса), эшчеләр

һөнәре, эш урынында стажировка оештыру өчен хезмәткәрләрнең вазыйфалары исемнәрен (әгәр стажировка өстәмә һөнәри программа формасы булмаса);

балигъ булмаган балалары булу турындагы мәгълүматны;

һөнәргә өйрәтү һәм (яки) стажировка оештыруда нигез булып торучы белем бирү программалары яктылыгында бу ихтыяҗны канәгатьләндерү өчен кирәкле эш эзләүче гражданнар санын күрсәтеп, эш эзләүче гражданнар арасыннан кадрларга булган өстәмә ихтыяҗ (булганда) турындагы мәгълүматны (стажировка өстәмә һөнәри программа формасы булса), эш урынында стажировка оештыру өчен хезмәткәрләрнең вазыйфалары, эшчеләр һөнәре исемнәрен (стажировка өстәмә һөнәри программа формасы булмаса).

Эш белән тәэмин итү үзәге гаризаны ул кергән көннән бер эш көне эчендә терки.

Эш белән тәэмин итү үзәкләре агымдагы елның 1 сентябреннән соңрак кертелгән гаризаларны кабул итми һәм карамый.

9. Эш белән тәэмин итү үзәге гариза теркәлгән көннән 2 эш көне эчендә гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны аларның бу Тәртип һәм бу Тәртипнең 8 нче пунктындагы беренче абзацта күрсәтелгән Министрлык боерыгында билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәү буенча карый.

Гариза билгеләнгән таләпләргә туры килгән очракта, эш белән тәэмин итү үзәге гаризаны карап бетергән көннән соң килүче эш көне эчендә оешмага, өч нөсхәдә субсидия бирү турындагы шартнамә проектын теркәп, гаризаны кабул итү хакында язма хәбәрнамә җибәрә.

Гариза күрсәтелгән таләпләргә туры килмәгән очракта, эш белән тәэмин итү үзәге гаризаны карап бетергән көннән соң килә торган эш көне эчендә оешмага гаризаны кире кагу турында, кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, язма хәбәрнамә җибәрә.

Оешма сораган субсидия күләме оешма өчен субсидиянең бу Тәртиптәге 12 нче пунктның уникенче абзацында күрсәтелгән формула буенча хисаплап чыгарылган иң чик күләменнән яки эш белән тәэмин итү үзәгенә субсидияләр бирү өчен билгеләнгән бюджет йөкләмәләре лимитларыннан артып киткән очракта, эш белән тәэмин итү үзәге гаризаны карап бетергән көннән соң килүче эш көне эчендә оешмага гаризаны кире кагу турында, оешма өчен субсидиянең иң чик күләмен һәм кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, язма хәбәрнамә җибәрә.

Гаризалар оешмаларга кире кайтарылмый һәм эш белән тәэмин итү үзәгендә билгеләнгән тәртиптә саклана.

10. Оешма субсидия бирү турындагы шартнамә проектын эш белән тәэмин итү үзәге җибәргән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көн эчендә өч нөсхәдә субсидия бирү турындагы шартнамәгә кул куярга һәм аны эш белән тәэмин итү үзәгенә җибәрергә тиеш.

Оешмадан субсидия бирү турындагы кул куелган шартнамәне алган көннән соң килүче бер эш көне эчендә эш белән тәэмин итү үзәге бу шартнамәгә кул куя һәм яклар тарафыннан кул куелган берәр нөсхәсен Министрлыкка һәм оешмага җибәрә.

11. Гаризасын эш белән тәэмин итү үзәге бу Тәртипнең 9 нчы пункты нигезендә кире каккан оешма гаризага эш белән тәэмин итү үзәгенең язма хәбәрнамәсендә күрсәтелгән кире кагу сәбәпләрен бетерү максатларында үзгәрешләр кертергә һәм аны кабат бу Тәртипнең 8 нче пунктында күрсәтелгән вакытларда эш белән тәэмин итү үзәгенә кертергә хокуклы.

Әгәр оешманың гаризасы бу Тәртипнең 9 нчы пункты нигезендә эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан өч тапкыр кире кагылса, эш белән тәэмин итү үзәге әлеге оешмадан алга таба гаризалар кабул итәргә рөхсәт итми. Бу очракта эш белән тәэмин итү үзәге оешмага өченче тапкыр гаризасын кире кагу турындагы язма хәбәрнамә белән бергә, кире кагу сәбәпләрен күрсәтеп, Министрлыкка оешманы Дәүләт программасында катнашучылар арасыннан чыгару процедурасын башлап җибәрү өчен гаризаларны кире кагу хакындагы барлык хәбәрнамәләре һәм оешманың барлык гаризалары күчермәләрен җибәрә.

12. Оешмага хезмәткәрләрне һөнәргә өйрәтү һәм (яки) аларның стажировкасы өчен бирелә торган субсидия күләме (Sоб) түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$S_{об} = N_{об} \times (С_{об} + С_{ст} \times Р_{об}) + N_{ст} \times 2С_{зп} \times Р_{ст},$$

монда:

$N_{об}$ – оешма һөнәргә өйрәтү өчен җибәрә торган хезмәткәрләр һәм эш эзләүче гражданнар саны;

$С_{об}$ – һөнәргә өйрәтүнең барлык чорында бер кешене һөнәргә өйрәтүнең уртача кыйммәте;

$С_{ст}$ – хезмәткәргә яки эш эзләүче гражданга һөнәргә өйрәнү чорында түләнә торган стипендия күләме, ул Татарстан Республикасында 2014 елның IV кварталында эшкә яраклы халык өчен билгеләнгән яшәү минимумының бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәре суммасына арттырылган күләменә тигез була;

$Р_{об}$ – һөнәргә өйрәтүнең өч айдан артмаган уртача чоры;

$N_{ст}$ – оешма стажировкага җибәрә торган хезмәткәрләр һәм эш эзләүче гражданнар саны;

$С_{зп}$ – стажировка үтү чорында уртача эш хакына чыгымнарны каплау күләме, ул Татарстан Республикасында 2014 елның IV кварталында эшкә яраклы халык өчен билгеләнгән яшәү минимумының бюджеттан тыш дәүләт фондларына иминият кертемнәре суммасына арттырылган күләменә тигез;

$Р_{ст}$ – стажировканың бер айдан артмаган чоры.

Оешмага хезмәткәрләрне һөнәргә өйрәтү һәм (яки) аларның стажировкасы өчен бирелә торган субсидия күләме оешма өчен субсидиянең иң чик күләменнән артып китәргә тиеш түгел, ул түбәндәге формула буенча хисаплап чыгарыла:

$$S_{обпред} = N_{об} \times (35909 \text{ сум} + С_{ст} \text{ X } 3 \text{ ай}) + N_{ст} \times 2С_{зп} \times 1 \text{ ай}.$$

13. Әгәр стажировка өстәмә һөнәри программа формасы булса, субсидия акчасы исәбеннән күрсәтелгән күләмдә бары тик стажировка үткән чорда уртача эш хакына тотылган чыгымнарны каплау гына гамәлгә ашырыла. Нинди дә булса башка түләүләр, шул исәптән стипендия түләү, стажировка үткән чорда белем бирү оешмалары күрсәткән хезмәтләр өчен түләү субсидия акчасы исәбеннән гамәлгә ашырылмый.

14. Хезмәткәрне яки эш эзләүче гражданны һөнәргә өйрәтү кыйммәтенә түбәндәгеләргә түләү чыгымнары кыйммәте кертелә:

белем бирү оешмалары күрсәтә торган хезмәтләр;

транспортта йөрү кыйммәте (һөнәргә өйрәтү урынына бару һәм аннан кире кайту) һәм һөнәргә өйрәнүченең һөнәргә өйрәнү чорында яшәвенә бәйле булган чыгымнар, хезмәткәр яки эш эзләүче граждан башка урында һөнәргә өйрәнгәндә (кирәк булганда);

махсус кием, махсус аяк киеме һәм башка индивидуаль саклану чаралары (кирәк булганда).

15. Оешмага эш белән тәэмин итү үзәге тарафыннан субсидия күчерү эш белән тәэмин итү үзәге субсидия бирү турындагы шартнамәгә кул куйганнан соң эш көннәрендә исәпләнә торган 7 көн эчендә оешманың хисап исәбенә субсидия бирү хакындагы шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла, бу вакытта эш белән тәэмин итү үзәге исәбендә әлеге максатларга күздә тотылган акча булу шарты үтәлергә тиеш.

16. Хезмәткәрләрне һәм эш эзләүче гражданнарны һөнәргә өйрәтүне һәм (яки) аларның стажировкасын оештыру, җитештерү шартларыннан, персоналның квалификациясенә карата таләпләрдән чыгып, оешма тарафыннан мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырыла.

Һөнәргә өйрәтү өчен белем бирү оешмаларын сайлап алуны оешма мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашыра, бу вакытта оешмага һөнәргә өйрәтү чыгымнары кыйммәтенең нигезле булуын, хезмәткәрләрне һәм эш эзләүче гражданнарны һөнәргә өйрәтү өчен таләп ителә торган белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруда уңай тәҗрибә булуны исәпкә алырга кирәк.

17. Оешма бер календарь елы эчендә бер хезмәткәрне һәм эш эзләүче бер гражданны иң күбе бер тапкыр һөнәргә өйрәтүгә һәм иң күбе бер тапкыр стажировкага җибәрергә хокуклы.

18. Оешма һөнәргә өйрәтүгә һәм (яки) стажировкага җибәрә торган хезмәткәр һәм эш эзләүче граждан белән хезмәт турындагы законнар нигезендә укучы шартнамәсе төзи.

19. Хезмәткәрләрне һәм эш ззләүче гражданнарны һөнәргә өйрәтү һәм аларның стажировкасы 2015 елның 25 декабренә кадәр төгәлләнергә тиеш.

20. Хезмәткәр һәм эш эзләүче граждан һөнәргә өйрәнүен һәм (яки) стажировкасын үтеп бетергәннән соң оешма эш көннәрендә исәпләнә торган 5 көн эчендә һөнәргә өйрәтүне тәмамлауны һәм (яки) стажировканы үтеп бетерүне, башка эш урынына күчерүне яки хезмәткәрнең оешмада эш урыны саклануны яки хезмәткәрне башка оешмага эшкә урнаштыруны, эш эзләүче гражданны эшкә

урнаштыруны раслый торган документларның күчермәләрен эш белән тәэмин итү үзәгенә кертә.

21. Һөнәргә өйрәтү һәм (яки) стажировка чорында оешманың хезмәткәрләре саны яки штаты кыскартылуга бәйле рәвештә хезмәткәрләр белән хезмәт шартнамәләрен өзү рөхсәт ителми.

Хезмәткәр оешмадан үз теләге белән киткән яки субсидия исәбеннән һөнәргә өйрәнү һәм (яки) стажировка уза торган хезмәткәр яки эш эзләүче граждан белән төзелгән укучы шартнамәсе өзелгән очракта, эштән азат ителү яки укучы шартнамәсе өзелгән вакытка кадәр һөнәргә өйрәтү өчен тотылган фактта расланган чыгымнарга түләү генә гамәлгә ашырыла, стажировка чорында стипендия түләү һәм уртача эш хакына тотылган чыгымнарны каплау эштән азат итү яки укучы шартнамәсен өзү датасына кадәр генә башкарыла.

## III. Субсидияләр бирү чыгымнарын финанслау тәртибе

22. Оешмаларга субсидияләр бирү чыгымнарын финанслау Дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасы хезмәт базарындагы киеренкелекне киметүгә юнәлдерелгән халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендәге өстәмә чараларны тормышка ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән гамәлгә ашырыла.

23. Министрлык Министрлыкның шәхси исәбенә акча керү турында Федераль казначылык идарәсеннән алынган чыгарма нигезендә Министрлык билгеләгән лимитлар нигезендә акчаны эш белән тәэмин итү үзәкләре исәпләренә күчерә.

24. Оешмаларга Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү чыгымнарын финанслауны Министрлык тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында бу максатларга күздә тотылган акча күләмнәре нигезендә гамәлгә ашыра.

25. Министрлык акчаны тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджетында күздә тотылган акча чикләрендә Министрлык билгеләгән лимитлар нигезендә эш белән тәэмин итү үзәкләре исәпләренә күчерә.

26. Эш белән тәэмин итү үзәкләре акчаны бу Тәртипнең 15 нче пункты нигезендә оешмаларга күчерә.

27. Субсидиянең агымдагы елның 31 декабренә кадәр файдаланылмый калган акчасын оешма 2016 елның беренче ун эш көне эчендә субсидияләр бирү турындагы шартнамәдә күздә тотылган очракларда эш белән тәэмин итү үзәгенә кире кайтарып бирергә тиеш.

## IV. Йомгаклау нигезләмәләре

28. Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы оешмаларга субсидияләр бирү өчен бүлеп бирелгән бюджет акчасыннан файдалану шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

29. Оешмаларга субсидияләр бирү өчен бүлеп бирелгән акча түбәндәге очракларда эш белән тәэмин итү үзәгенең тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә оешма тарафыннан эш белән тәэмин итү үзәгенә кире кайтарылырга тиеш:

оешманың дөрес булмаган мәгълүматлар һәм документлар кертү (шул исәптән хезмәткәрләрне һөнәргә өйрәтүгә һәм аларның стажировкасына чыгымнар буенча) фактлары ачыклану;

субсидиядән максатчан файдаланмау;

субсидия бирү турындагы шартнамәдә яки бу Тәртиптә каралган башка шартлар үтәлмәү.

Субсидиядән максатчан файдаланылмаган очракта, ул максатчан файдаланылмаган суммада кире кайтарылырга тиеш.

30. Әлеге акчаны кире кайтару вакыты бу Тәртипнең 29 нчы пунктында күрсәтелгән нигезләр буенча бозылган очракта, бу Тәртипнең 29 нчы пунктындагы беренче абзацта билгеләнгән вакыт чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 7 көн эчендә эш белән тәэмин итү үзәге күрсәтелгән акчаны гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү чараларын күрә.

Әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджеты кеременә үз ирекләре белән кире кайтарудан баш тартсалар, ул гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелергә тиеш.

31. Оешмаларга субсидияләр бирү өчен бүлеп бирелгән бюджет акчасыннан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту тотылган чыгымнарны раслый торган башлангыч документларны (төп нөсхәләрен һәм оешма тарафыннан таныкланган күчермәләрен) тикшерү, оешмага барып тикшерү үткәрү юлы белән Министрлык һәм эш белән тәэмин итү үзәкләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

_______________________________